РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» 04 2026 ел № 348

"2025-2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының комплекслы программасын" раслау турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында»гы 23.06.2016 ел, № 182-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында»гы 26.12.2016 ел, № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. "2025-2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының комплекслы программасын" (алга таба - Комплекслы программа) расларга.

2. Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән комплекслы программаны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетында каралган акчалар исәбеннән финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының "2025-2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Ютазы

муниципаль районының комплекслы программасын раслау турында"гы 23.05.2025 № 541 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

М.И Бурыкина
2-44-18

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты Карарына
кушымта
« 02 » 04 2026 ел № 348

**2025-2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының комплекслы программасы**

**1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2025-2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программасы паспорты**

| | |
|---|---|
| ***Программа исеме*** | **Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2025-2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программасы** (алга таба – Программа) |
| ***Программаның заказчысы - координаторы*** | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты |
| ***Программаны төп эшләүчеләр*** | - Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты<br>- Россия Эчке эшләр министрлыгының Ютазы районы буенча бүлеге<br>- Ютазы муниципаль районының "Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге" муниципаль казна учреждениесе<br>- "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе<br>- "Урыссу үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе<br>- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге<br>- "Ютазы муниципаль районы мәдәният бүлеге" муниципаль казна учреждениесе<br>- "Ютазы муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" дәүләт казна учреждениесе<br>- Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Ютазы муниципаль районындагы бүлеге<br>- Россия Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять башкарма инспекциясенең федераль казна учреждениесе<br>- Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге<br>- Баулы, Ютазы районнары һәм Баулы шәһәре буенча хәрби комиссариат |
| ***Программаның максаты*** | Хокук бозуларны профилактикалау системасын, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген ныгыту, әлеге эшчәнлеккә җирле үзидарә органнарын, иҗтимагый формированиеләрне һәм халыкны җәлеп итү, хокук бозуларны профилактикалауда һәм җинаятьчелеккә каршы көрәштә җирле үзидарә органнарының ролен һәм җаваплылыгын арттыру |
| ***Программаның бурычлары*** | 1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү; |

| | |
|---|---|
| | 2. хокук бозуларны профилактикалау буенча, барыннан да элек, эчкечелеккә, алкоголизмга, наркоманиягә, җинаятьчелеккә, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлегенә, законсыз миграциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән эшне активлаштыру;<br>3. иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү;<br>4. халыкка, иң элек яшьләргә һәм мәктәп яшендәге балаларга әхлакый тәрбия бирүне активлаштыру һәм камилләштерү;<br>5. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау буенча норматив хокукый базасын камилләштерү;<br>6. хокук бозуларны кисәтү мәсьәләләрендә җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләү;<br>7. хокук бозуларны кисәтүгә милекнең барлык рәвешләрендәге предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны, шулай ук иҗтимагый берләшмәләрне җәлеп итү;<br>8. гражданнарның хокукый хәбәрдарлык дәрәҗәсен һәм хокукый культурасын арттыру;<br>9. Эчке эшләр органнарының дежур частьләренең гражданнарның хокук бозулар турындагы гаризаларына һәм хәбәрләренә оператив мөнәсәбәте;<br>10. җәмәгать урыннарын алардагы хәлне тикшереп торуның техник чаралары белән тәэмин итү;<br>11. урамнарда һәм җәмәгать урыннарында кылынган хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау эшен оптимальләштерү;<br>12. экстремистик кәефләрне һәм күренешләрне, милли розгышны, раса һәм дини түземсезлекне профилактикалау;<br>13. хокук бозулар кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү |
| ***Программаны гамәлгә ашыру сроклары*** | Программа 2025-2028 еллар дәвамында гамәлгә ашырыла |
| ***Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары*** | 2025-2028 елларда программа чараларын үтәүгә Ютазы муниципаль районы бюджеты (алга таба – район бюджеты) акчалары исәбеннән 20 051,1 мең сум күләмендә финанс чыгымнары планлаштырыла. |

<table>
<tr>
<td></td>
<td>
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Ютазы муниципаль районы бюджеты акчалары (мең сум)</th></tr>
<tr><td>2025</td><td>5 115,7</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>4 640,2</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>4 910,6</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>5 384,6</td></tr>
<tr><td>Барлыгы:</td><td>20 051,1</td></tr>
</table>
Моннан тыш, чыгымнар да күздә тотыла:<br>бюджеттан тыш чыганаклар акчаларыннан;<br>гамәлдәге законнар белән тыелмаган башка чыганаклардан.<br>Күрсәтелгән чыганаклардан бүлеп бирелә торган акчалар күләме фаразлау характерында була һәм, ирешелгән нәтиҗәләр нигезендә Программа чаралары исемлеген, аларны гамәлгә ашыру срокларын һәм этапларын төгәлләштерүне исәпкә алып, тиешле финанс елына бюджет проектын формалаштырганда билгеләнгән тәртиптә ел саен төзәтелергә тиеш.
</td>
</tr>
<tr>
<td>Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td>
<td>Программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>- хокук бозуларны социаль профилактикалауның дәүләт системасының нәтиҗәлелеген арттырырга, хокук бозуларны кисәтү эшчәнлеген оештыруга предприятиеләрне, учреждениеләрне, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларны, шулай ук иҗтимагый оешмаларны җәлеп итәргә;<br>- хокук бозуларны профилактикалауны норматив хокукый җайга салуны тәэмин итәргә;<br>- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары һәм җәмәгать оешмалары эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне яхшыртырга;<br>- җәмәгать урыннарында, шул исәптән урамнарда кылынган җинаятьләрнең гомуми санын 2018 елда 9,3% тан 2028 елда 8,2% ка кадәр киметергә;<br>- балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең артуына юл куймау буенча профилактик чараларны дәвам итәргә;<br>- рецидив җинаятьчелек дәрәҗәсен киметергә, ягъни элек җинаять кылган затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләмен тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санынннан 2018 елда 28,5 % тан 2028 елда 23,9% ка кадәр киметергә;<br>- мөлкәти һәм икътисадый җинаятьләр санын кимету;</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | - "көнкүреш" җинаятьчелеге дәрәҗәсен киметергә, ягъни көнкүреш туфрагында кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләмен тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санынннан 2024 елда 24% тан 2028 елда 16% ка кадәр киметергә;<br>- исерек хәлдә кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләмен тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санынннан 2018 елдагы 45% тан 2028 елга 30% ка кадәр киметергә;<br>- наркотик һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьләр үсешенә юл куймаска;<br>- миграция агымнарын контрольдә тотуны көчәйтергә, законсыз мигрантлар санын киметергә;<br>- - халыкның хокук саклау органнарына ышаныч дәрәҗәсен арттыру. |
| ***Хокук бозуларны профилактикалау субъектлары эшчәнлеген координацияләү*** | Хокук бозуларны профилактикалау субъектлары эшчәнлеген координацияләү Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнә. |

## 2. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программалы чишүнең максатка ярашлылыгы

Татарстан Республикасы Президенты Указларын һәм Татарстан Республикасы законнарын, федераль һәм республика программаларын, шул исәптән җинаятьчелеккә каршы көрәш, наркотиклаштыруны профилактикалау, мәшгуль булмаган халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм социаль яклау, яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү һәм психологик ярдәм күрсәтү системасын үстерү буенча программаларны гамәлгә ашыру, шулай ук полиция участок уполномоченныйлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм аларны социаль-хокукый яклау дәрәҗәсен күтәрү буенча күрелә торган чаралар уңай йогынты ясый һәм билгеле бер дәрәҗәдә Ютазы муниципаль районында иҗтимагый иминлек торышын тотрыкландыруга ярдәм итә.

Уңай нәтиҗә кабул ителгән һәм гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 8 апрелендәге ПУ-127 санлы Указы белән расланган Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәт стратегиясеннән, «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 16.01.2015 ел, № 4-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 04.05.2006 ел, № 34-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Ютазы муниципаль районы Башлыгының «Ютазы муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру буенча район советы төзү һәм Ютазы муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәт программасын раслау турында»гы 2016 елның 11 маендагы 440 санлы, "Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында"гы 2017 елның 11 гыйнварындагы 3-ТРЗ санлы, "Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында"гы 2009 елның 21 гыйнварыннан 7-ТРЗ санлы, "Татарстан Республикасы территориясендә әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында"гы 2010 елның 2 ноябрендәге 80-ТРЗ санлы, "Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында"гы 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законнары, «Татарстан Республикасында алкоголь продукциясен, сыраны, тәмәкене чиктән тыш күп куллануны киметү һәм халык арасында сәламәт яшәү рәвешен булдыру буенча өстәмә чаралар турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 29 октябрендәге 867 номерлы карары, "Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауны көчәйтү буенча өстәмә чаралар турында"гы Татарстан Республикасы Президентының 2000 елның 24 маендагы ПУ-369 санлы Указы нигезендә көтелә.

Гражданнарның социаль яктан адаптацияләнмәгән аерым категорияләре иҗтимагый иминлек торышына бик тискәре йогынты ясый, алар арасында караучысыз калган балалар һәм яшүсмерләр, балигъ булмаган хокук бозучылар һәм иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче затлар, шулай ук санап үтелгән гражданнар категорияләрен реабилитацияләүнең чын мәгънәсендә нәтиҗәле

формаларының булмавы. Кабул ителә торган чараларның шактый өлеше таркау һәм тар ведомство характерында була.

2024 елда 9 ай эчендә, 2023 елның 9 ае белән чагыштырганда, җәмәгать урыннарында теркәлгән җинаятьләр саны 27 дән 21 гә кадәр кимегән, урамнарда үзгәрешсез калган - 10. Исерек хәлдә кылынганнарның 36 дан 39 га кадәр артуы күзәтелә. Көнкүреш нигездә кылынган җинаятьләр саны 17 дән 8 гә кадәр кимеде.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, балигъ булмаган затларга карата 5 АПГ (10) җинаять эше кузгатылган.

Җәмгыять һәм дәүләт тарафыннан тиешле профилактик каршылык күрсәтелмәгән эчкечелекнең киң таралуы җинаятьчелекнең торышына йогынты ясый торган җитди фактор булып кала бирә. Исерек хәлдә булган затлар тарафыннан бүген аларның гомуми саныннан 40% тан артык җинаять кылына.

Социаль профилактика системасының таркалуы, яшьләрнең мәшгуль булмавы һәм җәмгыятьтәге үзгәрешләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән башка объектив сәбәпләр яшүсмерләр җинаятьчелегенең тагын да үсүенә этәргеч бирә.

Җинаятьчелеккә каршы көрәш практикасы бүгенге көндә җирле үзидарә органнарының һәм иҗтимагый хәрәкәтләрнең тырышлыгын берләштерүне таләп итә. Хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләрен хәл итүдә тиешле финанс һәм матди-техник чаралар белән ныгытылган комплекслы якын килүне тәэмин иткән очракта гына тамырдан үзгәрешкә ирешергә мөмкин. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында бу өлкәдә хәлне яхшырту әлеге программа чараларына муниципаль һәм дәүләт ярдәме белән дә мөмкин.

## 3. Программаны гамәлгә ашыруның төп максатлары һәм бурычлары, сроклары һәм этаплары

Программаның төп максатлары хокук бозуларны профилактикалау системасын булдыру, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген ныгыту, әлеге эшчәнлеккә дәүләт органнарын, җәмәгать формированиеләрен һәм халыкны җәлеп итү, хокук бозуларны профилактикалауда һәм җинаятьчелеккә каршы көрәштә җирле үзидарә органнарының ролен һәм җаваплылыгын арттыру.

Программа түбәндәге бурычларны билгели:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү;

- хокук бозуларны профилактикалау буенча, барыннан да элек, эчкечелеккә, алкоголизмга, наркоманиягә, җинаятьчелеккә, балигъ булмаганнарның

күзәтүчесезлегенә, законсыз миграциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән эшне активлаштыру;

- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү;

– халыкка, бигрәк тә яшьләргә һәм мәктәп яшендәге балаларга әхлакый тәрбия бирүне активлаштыру һәм камилләштерү;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау буенча норматив хокукый базасын камилләштерү;

- хокук бозуларны кисәтү мәсьәләләрендә җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләү;

- хокук бозуларны кисәтүгә милекнең барлык рәвешләрендәге предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны, шулай ук иҗтимагый берләшмәләрне җәлеп итү;

- гражданнарның хокукый хәбәрдарлык дәрәҗәсен һәм хокукый культурасын арттыру;

- Эчке эшләр органнарының дежур частьләренең гражданнарның хокук бозу турындагы гаризаларына һәм хәбәрләренә оператив мөнәсәбәте;

- җәмәгать урыннарын андагы хәлне тикшереп торуның техник чаралары белән тәэмин итү;

- урамнарда һәм җәмәгать урыннарында кылынган хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау эшен оптимальләштерү;

- экстремистик кәефләрне һәм күренешләрне, милли розгышны, раса һәм дини түземсезлекне профилактикалау;

- хокук бозулар кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү.

Программа 2025-2028 еллар дәвамында гамәлгә ашырыла.

## 4. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны муниципаль районның Ютазы муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауның гомуми күләме **20 051,1 мең сум.**

| Ел | Ютазы муниципаль районы бюджеты акчалары (мең сумнарда) |
|---|---|
| 2025 | **5 115,7** |
| 2026 | **4 640,2** |
| 2027 | **4 910,6** |
| 2028 | **5 384,6** |
| Всего | **20 051,1** |

Программа чараларын гамәлгә ашыруга чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчаларны куллану күздә тотыла.

Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында була һәм Ютазы муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, тиешле елга Ютазы

муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда билгеләнгән тәртиптә ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

## 5. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны планлаштыру, үзара хезмәттәшлек итү, координацияләү һәм аның үтәлешен гомуми тикшереп торуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра, ул ел саен Программа чараларының максатчан күрсәткечләрен һәм чыгымнарын, программаны гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручылар составын төгәлләштерә, чараларны үтәү өчен җаваплы субъектлардан программаны үтәү барышы турында белешмәләр соратып ала.

Программаны гамәлгә ашыру чаралар исемлеге, аларны үтәү сроклары, бюджет ассигнованиеләре күрсәтелгән еллык план нигезендә гамәлгә ашырыла.

Программаны гамәлгә ашыру өчен җаваплы башкаручылар квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр, чараларны башкаручыларга тиешле бюджетлардан үсә барган йомгак белән һәм тулаем алганда хисап елында бүлеп бирелә торган чараларның үтәлеше һәм үзләштерелгән акчалар турында мәгълүмат тапшыралар.

Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты ел саен 1 мартка кадәр узган ел программаны гамәлгә ашыру турында Ютазы муниципаль районы Башлыгына һәм Ютазы муниципаль районы Советына йомгаклау доклады тапшыра.

Программа чараларын вакытында һәм сыйфатлы үтәүне тикшереп торуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

Программага үзгәрешләр кертү Программа чараларын җаваплы башкаручы тарафыннан йә билгеләнгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте йөкләмәләрен үтәү йөзеннән гамәлгә ашырыла.

Программа чараларының үтәлешен һәм финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссия утырышларында даими карау планлаштырыла.

.

# 6. Программа чаралары

## Ютазы муниципаль районының 2025-2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программасы чаралары буенча максатлар, бурычлар һәм финанслау

| Төп чаралар исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның билгеләре | | | | | Җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслау (мең сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2018 (база) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 7 | 8 | 9 | 10 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| **Максат: Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү** | | | | | | | | | | | | |
| **1 бурыч: Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү** | | | | | | | | | | | | |
| 1.1 "Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында" 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законны һәм "Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында" 2008 елның 13 октябрендәге 105-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү | ЮМР БК | 2025-2028 | ***100 мең кешегә кылынган җинаятьләр саны (берәмлек)*** | **993** | **870** | **850** | **830** | **810** | **834,9** | **758,2** | **831,8** | **912,3** |
| 1.2 Торак секторында өйдә эшләнгән спиртлы продукцияне (самогон) сату фактларын ачыклау, шулай ук халыкның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркынычсызлык таләпләренә җавап бирми торган контрафакт товарларны һәм алкоголь продукциясен әйләнештән алу, шулай ук балигъ булмаганнарга алкогольле һәм спиртлы продукцияне сату фактларын булдырмау буенча уртак профилактик чаралар уздырырга. | ОМВД, Дәүләт алкоголь инспекциясе, Авыл җирлекләре башлыклары | 2025-2028 | | | | | | | **-** | **-** | **-** | **-** |
| 1.3 финанс һәм матди кыйммәтләрне саклау объектларының техник җиһазландырылуын һәм янгын | ОМВД, МРО НДиПР ГУ МЧС РФ по | 2025-2028 | | | | | | | **-** | **-** | **-** | **-** |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| куркынычсызлыгын тикшереп торырга, җинаятьләр кылуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрелмәгәндә вазыйфаи затларны административ җаваплылыкка тартырга | РТ,<br>ОВО ВНГ РФ по РТ | | | | | | | | | | | |
| 1.4 социаль өлкә учреждениеләре (шул исәптән балалар клублары, балалар иҗаты үзәге, балалар сәнгать мәктәбе) территориясендә Коммерциячел, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның һәм башкаларның эшчәнлегенең законлылыгын тикшерергә. | ОМВД, ОСЗ,МКУ «ОДМС, МКУ «РОО», МКУ «ОК» ЮМР | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.5 социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр һәм балигъ булмаганнар турында мәгълүматлар базасын камилләштерергә | ЮМР БК, КДН и ЗП, ОСЗ, ГАУЗ «УЦРБ», МКУ «РОО», УИИ | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.6 социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләргә урнаштырылган караучысыз һәм күзәтүчесез балигъ булмаганнар турында мәгълүматлар базасын камилләштерергә | ЮМР БК, КДН и ЗП, ОМВД, ОСЗ, МКУ «РОО», ГАУЗ «УЦРБ» | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.7 билгеле бер яшәү һәм шөгыльләнү урыны булмаган затлар турында мәгълүматлар базасын камилләштерергә | ЮМР БК, ОМВД, ОСЗ | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.8 **автоматлаштырылган мәгълүматлар банкын камилләштерергә**: дәүләтнең аерым кайгыртуына мохтаҗ балигъ булмаганнар буенча мәгълүматлар базасын берләштерүче | МКУ «ОДМСТ», ООиП ЮМР БК, ГАУЗ «УЦРБ» | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.9 **автоматлаштырылган мәгълүматлар банкын камилләштерергә**: республиканың психиатрия һәм наркология | ГАУЗ «УЦРБ» | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| учреждениеләрендә күзәтү астында торучы затлар турында | | | | | | | | | | | | |
| 1.10 наркотиклар һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә катнашы булган затларның исәбен алып барырга | ОМВД | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.11 яшьләр арасында җинаятьчелек, наркомания һәм токсикомания, балаларның юл-транспорт травматизмы, сәламәт яшәү рәвеше, зарарлы гадәтләрнең зарарлы булуы, яшьләрнең рухи кыйммәтләргә юнәлеш тотуы һәм патриотизмны пропагандалау проблемалары буенча массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре үткәрергә | "Ютазы таңы" газетасы редакциясе, КТВ-Уруссу, МКУ «ОДМСТ», МКУ «РОО», ОМВД | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.12 массакүләм мәгълүмат чараларында: халыкның үз теләге белән корал һәм сугыш кирәк-яракларын тапшыру фактларын, җинаятьләрне булдырмауда һәм ачуда ярдәм итүне, наркотик матдәләрнең законсыз әйләнешенә бәйле, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы кылынган, шулай ук исерек хәлдә кылынган резонанслы җинаятьләрне яктыртырга | "Ютазы таңы" газетасы редакциясе, КТВ-Уруссу ОМВД | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.13. Массакүләм мәгълүмат чаралары төп профилактика методында – халыкка, беренче чиратта балигъ булмаганнарга һәм аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) наркотикларның зыяны, наркотикларны законсыз куллануга һәм сәламәт яшәү рәвешенә этәрүгә бәйле куркынычлар турында мәгълүмат бирүдә актив катнашырга тиеш. | "Ютазы таңы" газетасы редакциясе, КТВ-Уруссу | 2025-2028 | | | | | | | 3,0 | 3,0 | 3,0 | 3,0 |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.14 Программа чараларын мәгълүмати яктыртуны оештырырга | «Ютазы таңы» газетасы редакциясе, КТВ-Уруссу | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.15 әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудырган наркомания, йогышлы авырулар белән авыручы чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны ачыклау буенча сәламәтлек саклау учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлекне оештырырга. Вакытлыча яшәүгә рөхсәтне, эшкә рөхсәтне юкка чыгару буенча чаралар күрергә. | ОМВД, ГАУЗ «УЦРБ» | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.16 чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның килүен контрольдә тотуны оештырырга, миграция исәбендә тормаган затларны ачыкларга | ЮМР БК, ОМВД | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.17 район медицина учреждениеләрен наркотик һәм психотроп матдәләр куллану предметына тикшерү үткәрү өчен җиһазлар һәм чыгым материаллары белән тәэмин итү чараларын күрергә | ЮМР БК, ГАУЗ «УЦРБ» | 2025-2028 | | | | | | | 168,9 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| 1.18 наркотик һәм психотроп матдәләрне медицинадан тыш кулланучыларны иртә ачыклау максатыннан укучыларга һәм студентларга профилактик наркологик медицина тикшерүләре уздырырга. | ГАУЗ «УЦРБ», МКУ «РОО» | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.19 7-11 сыйныфларда укучыларга социаль - психологик тест үткәрергә | МКУ «РОО» | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.20 социаль-психологик тест нәтиҗәләре буенча "хәвеф-хәтәр төркеме"ндә укучыларга һөнәри тикшерү уздырырга | МКУ «РОО» ГАУЗ «УЦРБ» | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.22 ПДНда исәптә торучы делинктвент тәртипле балигъ булмаганнарга психиатр- | ГАУЗ «УЦРБ», ОМВД, КДН и ЗП | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| нарколог табиблар тарафыннан консультацияләр оештырырга | | | | | | | | | | | | |
| 1.23 наркотик, психотроп һәм токсик матдәләр, спиртлы эчемлекләр кулланучы балигъ булмаганнар, шулай ук караучысыз калган балалар, балигъ булмаган хокук бозучылар һәм имин булмаган гаиләләр турында ведомствоара мәгълүмат алмашуны гамәлгә ашырырга | ГАУЗ «УЦРБ», ОМВД, ОСЗ, КДН и ЗП | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.24 коррупциягә, ялган акчаларга, алкоголь һәм спиртлы продукциянең законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча оператив-профилактик чаралар уздырырга, аларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртырга, җәмәгать урыннарында агитация-реклама материаллары урнаштырырга («2015-2026 елларга ЮМРда коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» программасы нигезендә) | ЮМР БК, ОМВД, Дәүләт алкоголь инспекциясе, "Ютазы таңы" газетасы редакциясе, КТВ-Уруссу | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.25. Муниципаль учреждениеләргә кергәндә урнаштыру өчен корал, шартлаткыч җайланмалар (стационар металлорамкалар, киртәләр һ.б.) кулланып кылына торган җинаятьләрне, террорчылык актларын кисәтү һәм булдырмау өчен билгеләнгән булган махсус җиһазлар сатып алырга һәм алардан файдаланырга. | ЮМР БК | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | 140,0 |
| 1.26. Китапханәләр һәм социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре базасында өлкән яшьтәге гражданнар өчен «Финанс мошенниклыгы: ничек сакланырга», «Социаль челтәрләрдә һәм мессенджерларда куркынычсызлык» | ОСЗ, МКУ «ОК ЮМР» | | | | | | | | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| темаларына ай саен мәгърифәтчелек семинарлары һәм лекцияләр үткәрү. | | | | | | | | | | | | |
| 1.27. Районның гомуми белем бирү учреждениеләрендә «Киберкуркынычсызлык атналыгы»н оештыру һәм үткәрү, анда кибербуллинг, интернет челтәрендә хокуксыз гамәлләр өчен җаваплылык, шәхси мәгълүматларны яклау темалары буенча дәресләр үткәрү. | МКУ «РОО» | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.28. Күп функцияле үзәкләрдә, Саклык банкы һәм Россия почтасы бүлекчәләрендә, поликлиникаларда мошенниклыкның иң киң таралган схемалары һәм ашыгыч ярдәм күрсәтү өчен телефон номерлары турында кыскача мәгълүмат белән күрсәтмә памяткалар һәм листовкалар эшләү һәм тарату | МКУ «РОО», МКУ «ОДМСТ» | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.29. Киберкуркынычсызлык буенча даими мәгълүмати материалларны муниципаль районның рәсми сайтында һәм социаль челтәрләрдәге муниципаль пабликларда урнаштыру. | МКУ «РОО», “Ютазы таңы” газетасы редакциясе | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |
| 1.30. Дәүләт хезмәтләре Порталы һәм банкларның мобиль кушымталары аша кредит алуга «Үз-үзеңне тыю» билгеләү мөмкинлеге турында халыкка мәгълүмат бирү | “Ютазы таңы” газетасы редакциясе», район башлыгының матбугат сәркатибе, КТВ-Уруссу, МКУ «РОО», МКУ «ОДМСТ», МКУ «ОК», | 2025-2028 | | | | | | | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
